Бүгенге санда



Сайлау участокларыннан репортаж. 3нче бит


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Чәршәмбе 16 сентябрь 2015 ел

№ 68 (10597)


**17 сентябрьгә һава торышы:** алмашынучан болытлы һава, җил төньяк-көнчыгыштан 2-3 м/с; температура көндез +18°С, төнлә +11°С

## НУРЛАТЛЫЛАР ГРАЖДАНЛЫК АКТИВЛЫГЫ КҮРСӘТТЕ

Республика Президентын һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлаулар бездә сайлаучыларның зур активлыгы белән узды. Үзенең гражданлык позициясен белдергән, Бердәм тавыш бирү көнендә катнашкан, аны оештыруда үз өлешен керткән барлык нурлатлыларга рәхмәтемне җиткерәм. Территориаль сайлау комиссияләре, күзәтүчеләр, кандидатлар, барлык партия вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан зур эш башкарылды. Мин һәр сайлаучыга ышанычы, уйлап биргән тавышы өчен рәхмәтлемен. Республика перспектив үсеш һәм лидерлык юлына юнәлдерелгән курсын дәвам итәчәк. Бу безнең республика, безнең туган җиребез, һәм без аның белән горурланабыз. Бердәм тавыш бирү көне күрсәткәнчә, Татарстан көченә ышану дәрәҗәсе бик югары. Хөрмәтле нурлатлылар, сезнең ышанычыгыз барлык сайланган депутатлар өчен дә зур җаваплылык йөкли. Мин ышанам, без барыбыз да бердәм булып, яңа үрләр яуларбыз. Без бергә, без бердәм һәм көчле.

**Равил Кузюров,**
**Нурлат муниципаль районы башлыгы**

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## СЕЗОННЫ УҢЫШЛЫ БАШЛАДЫЛАР

Нурлат шикәр заводы чөгендер эшкәртү сезонын әйбәт башлап җибәрде. Сезон башыннан бирле биредә 27231 тонна татлы тамыр эшкәртелде.

Бүгенге көнгә предприятиедә 2737 тонна шикәр комы җитештерелде, диделәр заводта.

## НУРЛАТЛЫЛАР ХАҖ СӘФӘРЕНДӘ

Бу көннәрдә бер төркем нурлатлы хаҗ сәфәренә юл алды. Изге сәфәргә Нурлат мөселманнарын мөхтәсибәт вәкилләре һәм тәҗрибәле хаҗилар озатты. Мәккәдә хаҗилар Кече хаҗ кылырга, изге урыннарга экскурсияләргә барырга планлаштыралар. Ә аннан олы хаҗ гыйбадәтләре башланачак.


**Приглашаем на работу**
**ВАХТОВЫМ МЕТОДОМ**
*в Москве мужчин и женщин!*
**Мы предоставляем:**
*Высокую оплату труда*
*Бесплатное проживание*
*Еженедельные авансы*
*Корпоративный транспорт.*
**Звоните:**
**8 495 646 71 66,**
**8 966 135 61 88**
Реклама


# Сайлаулар – 2015: актив, бердәм үтте

**Нурлат районы һәм шәһәре буенча 2015 елның 13 сентябрендә узган Татарстан Республикасы Президентын сайлау нәтиҗәләре**

| № | ТСК исеме | Сайлаучылар саны | Килүчеләр % | һәр кандидат өчен тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның санынннан чыгып % | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Рушания Габделәхәт кызы Бильгильдиева % | Рөстәм Нургали улы Миннеханов % | Хафиз Гаяз улы Миргалимов % | Руслан Рафаил улы Йосыпов % |
| 1 | Нурлат районы | 18039 | 99,51 | 0,10 | 99,67 | 0,19 | 0,04 |
| 2 | Нурлат шәһәре | 27009 | 98,00 | 0,20 | 99,30 | 0,43 | 0,07 |
| **Район һәм шәһәр буенча нәтиҗәләр** | | 45048 | 98,60 | 0,16 | 99,45 | 0,33 | 0,06 |



Зилия Әксанова фотосы

**Район башлыгы Равил Кузюров гаиләсе белән тавыш бирде**

2334нче Нурлат – Төньяк сайлау участогына җәмәгате Эльмира Мәкъсумовна белән бергә тавыш бирергә килгән район башлыгы Равил Кузюров халыкның активлыгын билгеләп үтте.

- Нурлатлыларның актив һәм бердәм булып сайлауларга килүләрен бердәмлек күрсәткече дип саныйм, - диде район башлыгы. – Сайлауларны лаеклы, матур күрсәткечләр белән каршы алабыз, Нурлат командасы зур әзерлек эшләре алып барды. Мин шикләнмичә әйтә алам: нурлатлылар үз тавышларын лаеклы кандидатларга бирерләр, дөрес сайлау ясарлар. Без бергә, без бердәм, без көчле.

***

Нурлат районындагы барлык 60 сайлау участогында да ТР Президентын һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауда тавыш бирү иртәнге сәгать 7дә башланды. Нурлат урамы, 8нче йортта урнашкан 2332нче сайлау участогы сайлауны Россия һәм Татарстан гимннары белән ачты. Иң беренче тавыш бирүче "Чулпан" иминият компаниясенең Нурлат филиалы директоры Дамир Вәлиевның кулы җиңел булды. 7.01 сәгатьтә участокта җанлылык иде инде.

- "Һәр тавыш мөһим" акциясен яклап, бөтен коллективыбыз белән сайлауда катнашачакбыз. Участокларга иртәдән үк килергә сөйләштек, - диде Дамир Нәгыймович.

- Мин "Нурлатавтотранс" җәмгыятендә эшлим, болай да иртә торырга күнеккән кеше, эшне дә иртән башкарырга яратам, - ди Рөстәм Әбҗәпбаров. - Мин чын күңелдән киләчәк тормышның тагын да матуррак булачагына ышанып килдем.

– Һәркайсыбыз сайлауларның законлы узуы өчен тырыша. Без гадел сайлаулар яклы. – ди Нурлат – Көнчыгыш сайлау участогы рәисе Татьяна Соренкова.


– Бүген Нурлат районында ТР Президентын һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауда 27009 шәһәр һәм 18038 авыл сайлаучылары үз тавышларын бирәчәк. 321 яшь шәһәр гражданы, 261 яшь авыл сайлаучысы үз гражданлык хокукын беренче тапкыр башкарачак, – ди сайлаулар буенча җаваплы район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова. – Нурлат районы сайлауларда һәрвакыт бердәм фикердә һәм актив булды. Бу мөһим сайлауда да Нурлат халкы үз гражданлык бурычын үтәр, дөрес сайлау ясар, дип ышанам.

Сайлауда катнашучылар турындагы мәгълүмат ГАС "Выборы" системасын мәгълүматый тәэмин итү буенча 1 разрядлы белгеч Гөлназ Мөлековада туплана.

– Көн дәвамында без 10.00да, 12.00да, 15.00да, 18.00да ҮСКга мәгълүмат тапшырачакбыз, ә 20.00да соңгы нәтиҗәләрне туплап озатабыз, – ди Гөлназ.

*(Ахыры 3нче биттә)*

# Сайлаулар – 2015: актив, бердәм үтте



2334НЧЕ НУРЛАТ-ТӨНЬЯК САЙЛАУ УЧАСТОГЫ

*(Ахыры. Башы 1нче биттә)*

Фома сайлау участогында иртәнге 9га сайлаучыларның 20% тавыш бирде. Беренчеләрдән булып пенсионер Васыйл Мирзаҗанов килде. Ул авыл мулласы дога кылганнан соң тавышын бирде. Бу сайлау участогында 599 сайлаучы.

Тимерлек сайлау участогы. Шәһәрдән иң ерак урнашкан авыл кешеләре сайлауга сәгать 7дә үк килделәр. 417 сайлаучыдан сәгать 9га 15% тавыш биргән иде.

ТР Урман хуҗалыгы министры, район кураторы Алмас Нәзиров 13 сентябрьдә узган сайлауларда Нурлат шәһәре территориаль сайлау комиссиясенең киңәш хокукы булган әгъзасы буларак катнашты. Алмас Әминович район башлыгы Равил Кузюров, "Агроинвест" ИК генераль директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты Рәис Сөләйманов озатуында Нурлат – Завод, Нурлат – Мәскәү һәм Нурлат – Тимер юл сайлау участокларында булып, тавыш бирү барышы белән танышты, күзәтүчеләр белән аралашты, мониторингта катнашты. Район кураторы Нурлатта сайлауларның тыныч һәм җылы атмосферада узуын билгеләп үтте.

Кичке алтыларга сайлаучыларның күбесе үз тавышларын бирде.

Сәгать 6га шәһәр сайлау участокларында сайлаучылардан 87,84, район буенча 90,86 процент тавыш бирелде. Өйдә генә тавыш бирүчеләрнең иң зур пункты булып Нурлат интернат-йорты санала. Интернат-йорт җитәкчесе Евгений Савинов әйтүенчә, 120 өлкән кеше сайлауда катнаша. Алар өчен №2332 Нурлат–Көнчыгыш күчмә сайлау участогы үз өйләрендә үк сайлау мөмкинлеген оештырганнар. Интернат-йортта яшәүче Альберт Бикмөхәммәтов мондый сайлау шартлары алар өчен бик уңай, дип әйтте:


– Мин сайлауларны бик мөһим чара дип уйлыйм. Үзебездә сайларга мөмкинлек бирүләре дә бик әйбәт.

Сайлау участокларында сайлауларның уңышлы баруына хокук тәртибен саклаучылар тырышлыгы белән дә ирешелә. Полиция җитәкчесе урынбасары Дмитрий Фомин әйтүенчә, сайлаулар тәртип бозуларсыз бара. Сайлау участокларында 67 полиция, 15 шәхси сак предприятиесе хезмәткәрләре һәм ирекле халык дружиналарыннан барлыгы 30 кеше кизү тора. Район үзәк хастаханәсе, МЧС һәм полиция бүлегеннән хәбәр итүләренчә, сайлаулар белән бәйле гадәттән тыш хәлләр күзәтелмәгән. Сайлауларның чиста һәм гадел үтүе дә күз угында булды.

– Шәһәрдә сайлауларның барышын "Бердәм Россия" партиясеннән 17 күзәтүче, ТР Президентына кандидат Рөстәм Миннехановтан 16 күзәтүче һәм киңәш хокукына ия 17 участок комиссиясе әгъзасы күзәтте. Президентлыкка кандидатлар Рушания Бильгильдиевадан һәм Хафиз Миргалимовтан 2шәр күзәтүче, соңгысыннан 2 комиссия әгъзасы катнашты, – диде безгә шәһәр буенча опер-төркем җитәкчесе Марина Абрамова. – Алар тарафыннан бернинди хокук бозулар теркәлмәде.

**Зилия ӘКСАНОВА, Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА, Валентина ВАФИНА**

**Зилия ӘКСАНОВА фотолары**



ШӘҺӘР ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕНДӘ ЭШ КЫЗУ

ЯҢАЛЫК

# Яңа предприятие ачылды

**Районда тагы бер җитештерү предприятиесе ачылды: "Сервис хезмәтләре үзәге" ОООсы – насос-компрессор торбаларын ремонтлау һәм насос җиһазларын диагностикалау цехы. Биредә 50ләп эш урыны булдырылды. Бу әле чик түгел.**

Вакыйгада яңа предприятие коллективы белән бергә Нурлат муниципаль районы башлыгы Равил Кузюров, "Татнефтепром"ның генераль директоры Сергей Щелков, "ТНП-Зүзәйнефть" генераль директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты Шамил Яһудин, "Татех" ЯАҖ генераль директоры Ирек Хәйруллин да катнаштылар.

– Иң мөһиме, биредә кешеләр өчен эш урыннары булдырылды. Бу "ТНП-Зүзәйнефть" коллективы һәм тулаем район өчен дә бик мөһим,–диде район башлыгы Равил Кузюров цехны ачу тантанасында. Ул кече нефть компанияләре директорлар советына игелекле ниятләре, әйбәт нәтиҗә өчен рәхмәт белдерде.




ЯҢА ПРЕДПРИЯТИЕДӘ ЭШ УРЫННАРЫ БУЛДЫРЫЛДЫ

Вакыйга уңаеннан Сергей Щелков та үз котлауларын җиткерде.

– Безнең нык нефтьчеләр гаиләсендә тагы бер әйбәт предприятие барлыкка килде, – диде ул. – 25 ел дәвамында Татарстанда кече нефть компанияләре күп структуралар булдырдылар, әмма бу цех – тулы төгәлләнгән циклдагы предприятиеләрнең беренчеләреннән әле.

"Сервис хезмәтләре үзәге"нең генераль директоры Рушан Хөсәенов әйтүенчә, цех әлегә бер сменада эшли, анда 50ләп кеше җәлеп ителәчәк.

– Хәзерге вакытка ике – НКТ һәм насос штангаларын ремонтлау линияләре ачылды. Цех бар иде инде, анда реконструкция үткәрелде, җитештерү эстакадалары, су-шлак аеру участогы төзелде, – диде ул. Цех бер сменада 240 насос-компрессор торбаларын ремонтлау, 200 насос штангасын диагностикалауга көйләнгән. Рушан Хөсәенов әйтүенчә, киләчәктә цехны тәүлек әйләнәсенә 4 сменада эшләтү мөмкинлеге дә карала. Кыскасы, кече нефть компанияләренең бу җәһәттән проблемалары булмаячак. Болардан тыш, цех әле аларга транспорт хезмәте дә күрсәтәчәк.

Предприятиене ачу тантаналы шартларда барды. Цехны ачуда күп хезмәт куйган белгечләр һәм эшчеләргә бүләкләр дә тапшырылды, концерт номерлары да булды.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

БЕР УЧ ХӘБӘР

## БУРЫЧЛАР БИЛГЕЛӘНДЕ

**Узган атнада Мәдәният сараенда районның ветераннар (пенсионерлар) оешмасы Советының планлы утырышы үтте.**

Анда совет рәисе Разия Садретдинова ел дәвамында башкарылган эшләргә йомгак ясады һәм алдагы чорга планнар белән таныштырды. Утырышта район башкарма комитетының эшләр белән идарә итүчесе Ралия Ханиева да катнашты. Очрашуда алда торган сайлаулар, Өлкәннәр һәм Инвалидлар көннәренә әзерлек мәсьәләләре каралды. Мәдәният йортларында пенсионерлар өчен мәдәни чаралар, түгәрәкләр оештырырга дигән тәкъдимнәр керде.

- Аралашу өлкәннәр тормышына яңа импульс бирә. Әйдәгез, төрле чаралар, бәйгеләр оештырыйк, өлкәннәрне актив тормышка җәлеп итик, боларның барысы да өстәмә энергия бирә һәм тормышыбызны ямьләндерергә булыша бит, - ди Разия Садретдинова.

Утырышта шулай ук "Иң матур ишегалды" конкурсы үткәрү мәсьәләсе дә каралды.

**Гүзәлия МӘХМҮТОВА**

## БЕЗ ТАГЫН БЕРЕНЧЕ

**Һава температурасы 5 тәүлек +8 градустан түбәнрәк торса, рәсми рәвештә, Россиядә өйләргә җылылык бирәләр иде.**

РФның Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы ягу сезонының башлану һәм төгәлләнү срокларына кагылышлы закон проектын тәкъдим итте – җылылыкны кайчан бирергә һәм туктатырга икәнлеген һәр төбәк үзе хәл итәчәк. Нурлатка бу кагылмый, чөнки без күптән инде шулай яшибез.

– Татарстан өчен бу яңалык түгел, – ди Нурлат җылылык челтәрләре предприятиесе директоры Рамил Шарапов. – Әгәр климатик шартлар шуны таләп итә икән, һәм һава торышы бозылса, без ягу сезонын башлыйбыз. Режимга карамастан, 2013 һәм 2014 елларда безнең предприятие республикада беренчеләрдән булып җылылык бирә башлады.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

## КАМА АРЪЯГЫ ЗОНАСЫ БАШ КАЗЫЕ НУРЛАТТА ҖОМГА НАМАЗЫ ҮТКӘРДЕ

**Узган атнада шәһәрдә Кама арьягы зонасы баш казые, Чистай районы мөхтәсибе Алмаз хәзрәт Шәрифуллин булып китте.**

Әлеге визит Экстремизмга каршы айлык кысаларында һәм тәҗрибә уртаклашу максатыннан оештырылган иде. Нурлат мөселманнары белән очрашу үзәк дин йорты – базар яны мәчетендә үтте.

– Нурлат районында динле халык яши, - дип үз фикерләре белән бүлеште баш казый. Һәм Нурлат мөселманнарына мөрәҗәгатен дә җиткерде. – Үзәк мәчет – шәһәрнең һәм анда яшәүче мөселманнарның йөзе. Әлеге Аллаһ йорты өчен җаваплылык имам җилкәсендә. Мәчетләргә йөрүче мөселманнарыбыз иман йортларының торышына битараф булмасыннар иде.

Алмаз хәзрәт Шәрифуллин шунда ук җомга намазын үткәрде, мөселманнарга вәгазь сөйләде, нурлатлыларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирде.

**Зилия ӘКСАНОВА**

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Иске Әмзә авылында** гомер итүче **Илдар Барис улы Гильмушовның** 15 сентябрьдә 50 яшьлек юбилее.

Кадерлебез, сиңа таза исәнлек телибез, балаларыңның шатлыкларын гына күреп яшәргә язсын.

Тормыш юлың һәрчак
балкып торсын,
Нурлы булсын синең көннәрең.
Сәламәт бул, ак бәхетләр белән
Гел шатлыкта үтсен һәр көнең.

**Иң изге теләкләр белән әниең, тормыш иптәшең, балаларың.**

**Яңа Әлмәт авылында** гомер итүче сөекле әниебез, дәү әниебез **Вәсимә Хәбибулла кызы Нәбиуллинаны** туган көне белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез.

Һәммәбезне сөеп
үстердең син,
Һәммәбезгә җитте назларың.
Игелегең өчен рәхмәт, әнкәй,
Сагына калсаң гомер язларың,
Оныттырыр моңсу сагышыңны
Оныкларың килеп сыенса.
Иң сөекле, иң кадерле булып,
Яшә әле, әнкәй, боекма!
Син бердәнбер безгә, онытма!

**Балаларың, киявләрең, киленнәрең, оныкларың.**

**Киекле авылында** яшәүче кадерле әниебез **Рәйсә Сәмигулла кызы Ишмуратованы** 17 сентябрьдә озачак гомер бәйрәме – 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз.

Әниебез – безнең кадерлебез,
Без бәхетле җирдә син барга,
Фәрештәләр кунсын иңнәреңә
Туган көнең белән котларга.
Төрле чакны күргәнсеңдер, әни,
Йөрәгеңдә күптер яра да,
Киңәшчебез, терәгебез булып,
Озак яшә безнең арада.

**Иң изге теләкләр белән кызларың, киявләрең, оныкларың.**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*дом, варианты. Т. 8-919-684-40-03.

*3-комнатная квартира, ул. Советская, 195; дом, ул. Советская, 17; 2-комнатная квартира, ул. Ст.Разина, 4. Т. 8-927-243-65-08.

*дом, с. Фомкино; земельный участок, Тарн.Варн, 17,5 соток; дом, ул. Кутузова. Т. 8-9274-222-456.

*1-комнатная квартира, ул. Мира; 3-комнатная квартира, ул. К.Маркса. Т. 8-937-77-40-132.

*дачный участок в районе 4 школы. Т. 8-927-047-59-71.

*дом. Т. 2-04-04.

*дом, с. Егоркино. Т. 8-937-441-07-56.

*3-комнатная квартира по ул. Кариева. Т. 8-927-457-40-44.

*1-комнатная квартира, центр. Т. 8-927-039-97-64.

*кирпичный дом в Средних Челнах или обменивается на 1-комнатную в Нурлате. 8-937-626-01-80.

*дом в Ключах, недорого. Т. 8-965-623-69-29.

*срочно 2-этажный дом, ул. Ахметова, 32, черновая отделка. Т. 8-927-409-48-88. *2-комнатная квартира, ул. Нурлатская, 18; участок с домиком под дачу, д. Бурметьево. Т. 8-927-435-99-35.

*2-комнатная квартира, с/з. Т. 8-937-576-02-73.

*срочно 2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 19. Т. 8-927-675-37-23.

*1-комнатная квартира, ул. Садовая. Т.: 8-937-598-86-37, 8-937-280-97-98.

*коттедж, ул. 1-Дачная, 28. Т. 8-927-047-41-24.

*гараж, ул. Дружбы, за домом №60. Т. 8-927-461-60-41.

*1-комнатная квартира, ул. Дружбы, 600 тыс.руб., 2-комнатная, ул. Гагарина, 2, 830 тыс.руб., жилой дом, ул. Кутузова, 1450 тыс.руб., новый коттедж, ул. Юбилейная, 4 млн.руб., коммерческое помещение, 1 млн.руб. Т. 8-929-727-12-82, Ксения.

***1-комнатная квартира**, пер. Заводской, 6, 650 тыс.руб., **1-комнатная**, ул. Нефтяников, 9, ремонт, 730 тыс.руб., **2-комнатная**, ул. Циолковского, 7, 760 тыс.руб., **2-комнатная** ул. Дружбы, 69, 1160 тыс.руб., дом, с. Курманаево, 80000 руб., **недострой из сосны,** ул. Центральная, 54, **недострой**, ул. Куйбышева, 64, 750 тыс.руб., **недострой**, ул. Дальняя, 1, 910 тыс.руб., **2-комнатная,** ул. Нурлатская, 33, 1200 тыс.руб. Т. 8-937-600-47-73.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«Приора», седан, 2012. Т. 8-937-294-17-88.

*трактор «МТЗ-320», 2014 г/в, кун, ковш, вилы. Т. 8-917-159-86-99.

*«ВАЗ-2105», 2006 г/в. Т. 8-927-436-17-35.

*«Волга», 2003 г/в. Т. 8-937-616-57-41.

*«ВАЗ-2105», 2006 г/в. Т. 8-927-431-25-07.

*«ВАЗ-21099», 2001 г/в, без вложений, торг. Т. 8-927-441-81-61.

*«Шевроле Спарк», 2009 г/в, пробег 42000 км. Т. 8-927-434-47-05.

*«Дэу Нексия», 2012 г/в, отличное состояние, вложений не требует, люкс, кондиционер, ГУР, музыка, ЦЗ. Т. 8-927-032-57-08.

*«Волга-31010» (1997 г/в) или обменивается на откормленного быка. Т. 8-927-675-46-51.

*«УАЗ-452» (микроавтобус). Т. 8-927-671-67-97.

*«Ауди-80» на запчасти. Т. 8-927-419-93-78.

*«ВАЗ-21074», 2010 г/в, цвет черный, 110 тыс.руб. Т. 8-927-417-51-78.

*«Лада Гранта», лифтбек, октябрь 2014 г/в. Т. 8-927-467-42-69.

*«Приора», 2007 г/в. Т. 8-927-763-03-36. *«ВАЗ-2107», 2007 г/в. Т. 8-917-265-70-19.

*«Нива-2121», зеленая, 1979 г/в, 50000. Т. 8-937-600-33-02.

*«Форд Мондео», 1998 г/в; «Сузуки Гранд Витара», 2010 г/в, в отличном состоянии. Т. 8-927-492-84-20.

*«Форд Фокус3», 2012 г/в, 530 тыс.руб.; ДТ-75 бульдозер, плуг 4 корпуса, МТЗ-80 с тележкой. Т. 3-72-90.

## ДРУГОЕ

*бычки, куры-молодки, бройлеры, несушки, утки, гуси. Т.: 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.

*бычки, молодняк, от 2 до 5 м. Т. 8-927-870-58-98.

*ПГС, песок, бут. Т. 8-927-402-13-40.

*бычки. Т. 8-927-987-87-63.

*песок, ПГС, бут, цемент, перегной, чернозем, щебень, керамзит. Т. 8-937-287-45-40.

*ПГС, бут, песок, перегной, чернозем, цемент, щебень, керамзит. Т. 8-927-401-51-91.

*глина, песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.

*бычки молодняк. Т. 8-927-880-12-83.

*поросята. Т. 4-32-77.

*овцы, бараны, ярки. Т. 8-927-766-94-17.

*куры, утки. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.

*ПГС, бут, песок. Т. 8-987-283-18-34.

*бут, ПГС, песок, перегной. Т.: 8-927-675-54-96, 8-917-248-21-66.

*кобыла, 3 года, порода Орловка. Т. 8-927-760-60-23.

*овцы. Т. 8-927-200-18-27.

*чернозем, перегной, грунтощебень, бут. Т. 8-927-463-63-17.

*поросята. Т. 8-937-770-46-59.

*овцы (Курбан-байрам). Т. 8-927-448-04-76.

*прихожая, б/у. Т. 8-937-620-00-18.

*хлеб черствый, 250 руб. мешок. Т. 8-927-600-27-05.

*картошка деревенская, доставка; телка стельная на племя, отел в октябре. Т.: 8-927-413-05-92, 3-55-64.

*срубы бани 5,5х3,5, дом 6х8, недорого. Т. 8-927-475-94-24.

*керамблоки. Доставка. Т. 8-917-265-19-61. *картофель, возможна доставка. Т. 8-937-616-49-46.

*витрина. Т. 8-927-246-09-80.

*семена – костер, люцерна. Т. 8-927-470-39-02.

*перегной, песок, ПГС, глина от 3т. Т. 8-927-424-02-83.

*картофель. Т. 8-917-233-50-91.

*картошка желтая, доставка. Т. 8-927-401-12-17.

*картошка, дешево. Т.: 8-917-912-79-66, 8-927-428-04-52.

*перепелиные яйца, доставка. Т. 8-927-671-67-97.

*картошка, доставка на дом. Т. 8-927-412-39-30.

*телка стельная. Т. 8-927-474-11-49.

*перегной, дрова колотые. Т. 8-937-583-35-80.

*картошка крупная, 100 руб. ведро. Т. 8-937-775-97-25.

*картофель. Т. 8-927-426-36-29.

*картофель. Т. 8-937-285-99-31.

*шифер, б/у, дешево. Т. 8-927-242-76-55. *прихожая. Т. 8-927-470-35-59.

*коза дойная годовалая, козы восьмимесячные. Т. 2-29-30, дом.

*помидоры. Т. 8-937-593-08-66.

*теленок, 2 месяца. Т. 8-927-723-70-36.

*бараны. Т. 8-927-671-39-88.

*бычок, 1,5 года. Т. 8-927-670-26-47.

*картофель, самовывоз. Т. 8-937-003-17-90.

*козочка. Т. 8-927-455-24-78.

*картошка. Т.: 8-927-446-36-14, 4-35-90, Средняя Камышла.

*бычок. Т. 8-927-245-28-06.

*столы журнальный, раскладной, недорого. Т. 8-927-247-07-22.

## РАЗНОЕ

*грузоперевозки «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.

*перетяжка, ремонт мягкой мебели. Т. 8-937-570-60-21.

*услуги погрузчика. Т. 8-927-402-13-40.

*тамада. Т. 8-960-088-23-94.

*кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.

*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.

*установка окон, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.

*тамада. Т. 8-917-880-58-82.

*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.

*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*ремонтно-отделочные работы, гипсокартон, ламинат, плитка. Т.: 8-987-971-15-18, 8-937-290-03-54 (Геннадий).

*сантехника (вода, канализация, отопление). Т. 8-937-526-56-86.

*вспашка земли. Т. 8-927-481-29-70.

*грузоперевозки, «ГАЗель», длина 4,20, межгород. Т. 8-927-437-40-78.

*ремонт компьютеров, установка программ. Т. 8-927-485-70-65.

*ищу работу программистом, системным администратором. Т. 8-927-485-70-65.

*все виды отделочных работ. Качественно, недорого. Т. 8-937-611-98-03.

*услуги электрика. Т. 8-937-614-70-15.г/п. Т. 8-927-401-11-76.

*отделы «Серебро» и «Срочный ремонт одежды» переехали в парикмахерскую, вход со стороны «ЭССЕН». Т. 8-927-248-41-39.

*19, 20 сентября в мкр. Нижний Нурлат на кладбище проводится субботник.

*копаем, чистим колодцы. Т. 8-987-274-95-46.

*копаем, заливаем фундаменты, выполняем бетонные работы. Т. 8-937-294-65-52.

*копаем, чистим колодцы, копаем траншеи, канализации. Т. 8-937-776-79-45.

*выравнивание стен, потолков, обои. Т. 8-937-288-61-40.

*дипломы, курсовые. Т. 8-927-402-25-12.

*татуаш, маникюр, педикюр, макияж. Т. 8-927-402-25-12.


*грузоперевозки «Зил» (бычок) по РФ. Т. 8-987-038-87-90.

*отдам щенят в хорошие руки. Т. 8-927-412-23-68.


ВНИМАНИЕ!!!

Только с 1 по 30 сентября 2015 г.

Компания "Оконные системы"




Окно 1300х1400
Подоконник 300 мм
Отлив 150мм
Монтаж с демонтажем

При заказе более 2-х окон

ПОДАРОК до 1000р с окна*

| Rehau | KBE | Montblanc | Exprof |
| --- | --- | --- | --- |
| 7700руб | 7200руб | 6500руб | 6000руб |

т. 8-927-742-66-67, 8-908-383-89-98

*Подробности по указанным телефонам. Организатор: ООО "СВК". Реклама


## СДАЕТСЯ

*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.

*квартира посуточно. Т. 8-927-456-05-69. *1-комнатная квартира. Т. 8-929-724-84-17. *помещение, ул. Салимжанова, 82 кв.м, свободного назначения. Т. 8-927-242-59-26.

## ТРЕБУЕТСЯ

*охранники, вахта 2 недели / 2 недели, доставка, проживание, питание + соц. пакет, з/п от 850-900 руб./сутки ( без лицензии), 900 - 1000 руб./сутки ( с лицензией ). Т. 8-937-986-76-81.

*электрик. Т. 8-917-398-26-41.

*уборщик (-ца). Т. 8-927-032-73-42.

*продавец. Т. 8-927-032-73-42.

*монтажники. Т. 8-987-225-50-02.

*в ООО «Перспектива» водители, крановщик. Справки по тел.: 2-58-21, 2-58-22, по адресу: г.Нурлат, ул. Заводская, 1.

*ЗАО «Нурлатский элеватор» на постоянную работу мастер по подготовке газа, электромонтер по обслуживанию и ремонту электрооборудования. Т. 2-00-28.

*няня. Т. 8-927-246-54-47.

*ООО «Ремстрой» обмотчик эл.машин. Т. 8-917-860-37-98.

*срочно консультанты в ФС «Мегафон» («Эссен»). Т. 8-937-770-57-67.

*слесарь КИПиА, 4-5 разряда с л/а. Т. 8-927-433-19-67.

*ухаживающий (ая) с проживанием. Т. 8-927-492-46-12.

*продавец в продуктовый магазин. Т.: 8-927-443-80-43, 8-919-644-51-41.

*водитель в госучреждение. Т. 8-927-248-48-04.

*разнорабочий. Т.: 2-78-66, 8-937-770-11-72

.*в редакцию районной газеты творческие работники со знанием русского и татарского языков. Т. 2-36-14.

## КУПЛЮ

*«ВАЗ» переднеприводный, иномарки. ДОРОГО. Т. 8-927-456-00-07.

*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.

*КУПЛЮ АВТО. ДОРОГО. Т. 8-937-588-36-46.

*КРС, шкуры КРС. Т. 8-927-412-29-99.

*дом. Т. 8-927-695-33-66.

*б/у радиатор на «ГАЗ-53». Т. 8-937-286-09-25.

## ОБМЕН

*3-комнатная квартира, ул. Кариева, 12, мкр. РИТЭК на дом или на квартиру. Варианты. Т.: 2-49-40, 8-927-458-57-95.

*дом на 2- или 3-комнатную квартиру с доплатой. Т. 8-929-727-45-34.

## ПОТЕРИ

*документы на имя Фаиля Фаткулловича Кабирова просим вернуть за вознаграждение. Т. 8-937-615-98-51.


*Кирпич огнеупорный, силикатный, бой кирпича, швеллера, балки двутавровые, разных диаметров, трубы диаметром от 25 до 100, листовое железо.*
**Т. 8-927-492-84-20.**


## Рәхмәт белдерәбез!

Киекле авылында гомер иткән **Нәбиулла Хөснулла улы ХӘЙРУЛЛИННЫ** соңгы юлга озатканда ярдәм кулы сузган авылдашларга, дусларга, туганнарга, мәчет картларына, күршеләргә олы рәхмәтебезне белдерәбез. Сезгә исәнлек-саулык, бәрәкәтле тормыш телибез.

**Рифгать, Гөлия**

## Кайгы уртаклашабыз

"Коммунальник" ТСЖсы коллективы, **Илназ Илгиз улы МӨБАРӘКШИННЫҢ** вакытсыз вафат булуы сәбәпле мәрхүмнең тормыш иптәше балалары, әнисенең, якыннарының кайгыларын уртаклаша, хәсрәтле көннәрендә сабырлык тели.

***

"Нурлат" ТРКсы коллективы **Илназ Илгиз улы МӨБАРӘКШИННЫҢ** вакытсыз вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсенең, якыннарының, туганнарының кайгыларын уртаклаша, сабырлык тели.

***

ТР Нурлат муниципаль районының мәгариф бүлеге һәм профсоюз оешмаларының Нурлат Советы, әтиләренең вафаты сәбәпле, шәһәрнең 4нче урта мәктәбе директоры **Солтан Фәйзерахман улы ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ** һәм башлангыч сыйныфлар укытучысы **Раилә Фәйзрахман кызы ЗӘЙНИЕВАНЫҢ** авыр кайгыларын уртаклаша, сабырлык тели.

***

Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, "Форпост" яшьләр формированиесе, балалар – үсмерләр спорт мәктәпләре һәм барлык спортчылар, **Илназ Илгиз улы МӨБАРӘКШИННЫҢ** вакытсыз вафаты сәбәпле, мәрхүмнең тормыш иптәше Лилиянең, уллары Булат белән Камилнең, туганнарының, якыннарының авыр кайгыларын уртаклашалар, хәсрәтле көннәрдә сабырлык телиләр.

***

Тормыш иптәше **Илназ Илгиз улы МӨБАРӘКШИННЫҢ** вакытсыз вафат булуы сәбәпле, сыйныф җитәкчебез Лилия Мирзаҗан кызы Мөбарәкшинаның, балаларының, якыннарының тирән кайгыларын уртаклашабыз, хәсрәтле көннәрендә түземлек һәм сабырлык телибез.

**Биккол урта мәктәбенең 2001нче елгы чыгарылыш укучылары**


Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ www.tatmedia.ru www.nurlat-tat.ru

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы
Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

"Татмедиа" АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина
Тел.: 2-36-14

Редакциянең адресы:
423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19
Электрон адрес: e-mail: redak@list.ru
Телефоннар: 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс
2-36-20 – рус бүлеге
2-36-13 - корреспондентлар
2-25-88 – бухгалтерия

Нәшер итүче:
"ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маенда теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018
Бу сан "Татмедиа" АҖ филиалы
"Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды
Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.
Басуга тапшыру вакыты:
график буенча – 14.30,
фактта – 14.30

татмедиа

Тираж - 1643

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.
**Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
Реклама белдерүләренең төгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Газета **чәршәмбе** һәм **җомга** чыга.
Заказ №5978
Язылу индексы – 16185
Бәясе ирекле.

12+


© Язмаларны күчереп бастыру редакциянең язмача рөхсәте белән генә мөмкин.

КЫЗЫЛ. САРЫ. ЯШЕЛ

# Автошәһәрчек иминлеккә өйрәтә



Автор фотосы

АДМИНИСТРАТИВ ПРАКТИКА ИНСПЕКТОРЫ МАРАТ НУРУЛЛИН ЯШЬ ҖӘЯҮЛЕЛӘРГӘ ЮЛ ДОКУМЕНТЛАРЫ ТАПШЫРА

**Шәһәрдә беренче автошәһәрчек – "Әкият" балалар бакчасында пәйда булды. Әлеге зур бүләкне Нурлат балаларына ТРның баш дәүләт инспекторы Рифкат Миннеханов ясады.**

- Узган елның июль аенда Рифкат Нургалиевичның Нурлатка визиты барышында баш дәүләт инспекторы безнең балалар бакчасында кунакта булган иде, - ди бакча мөдире Фәйрүзә Якупова. – Ул вакытта безнең бакчага 4 велосипед бүләк итсә, өстәп балалар автошәһәрчеге булачагын да хәбәр иткән иде. Бер ел дигәндә безнең балалар бакчасында барлык мөмкинлекләр – юл билгеләре, разметкасы, светофор макетлары булган уку-өйрәнү мәйданчыгы барлыкка килде. Хәзер безнең балалар бакчасына йөрүче нәниләр юл хәрәкәте кагыйдәләренең нечкәлекләрен автошәһәрчекнең үзендә өйрәнәчәк.

Уку мәйданчыгында бар да зурларныкы кебек: юл билгеләре, светофор, җәяүлеләр юлы белән җиһазландырылган һәм асфальтланган мәйданчык. Мондый мәйданчыкка шәһәрдәге автомәктәпләр дә көнләшерлек. Коллективның, балаларның шатлыгын уртаклашырга килгән район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхать Габдуллин әлеге вакыйганың мөһимлеген билгеләп үтте.

- Районда көн саен транспорт чаралары артып торган заманда, балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтү, алар-да имин хәрәкәт культурасы тәрбияләү мөһим. Балалар белән эшләүдә яңа махсус методика булган заманча бу автошәһәрчек шәһәрнең башка балалар бакчалары өчен дә файдалы булсын. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнү буенча гамәли дәресләр бирелә узсын.

Яшь юл инспекторларын котларга район башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары Линар Маняпов, ЮХИДИ бүлеге начальнигы Рөстәм Гарипов та килгән иде.

- Автошәһәрчекне ачу – күптән көтелгән вакыйга, ул районның барлык мәктәпкәчә белем бирү системасы өчен зур бәйрәм, - диде Линар Маняпов. – Әлеге комплекс балаларга уен формасында имин һәм һәлакәтләрсез күнекмәләр алырга ярдәм итәчәк.

- Бала бик яшьтән юл хәрәкәтендә катнашучыга әверелә, - ди ЮХИДИ бүлеге җитәкчесе Рөстәм Гарипов. - Юл һәм урам баланы сыналмаган яклары белән үзенә тарта. Шуңа да балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләренә үзвакытында өйрәтергә кирәк. Бу максатка тәрбиячеләр, педагоглар һәм әти-әниләр, инспекторлар бердәм булып эшләргә тиеш.

Тантаналы өлештән соң "Әкият" балалар бакчасына йөрүче нәниләр һәм аларның тәрбиячеләре кунакларга шәһәр урамы макетын кулланып, юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча теоретик дәрес фрагментларыда күрсәттеләр, юл билгеләре һәм терминнар кулланып, үз чыгышларын тәкъдим иттеләр.

Зилия ӘКСАНОВА

КЫСКАЧА

## БИБЛИОКАРАВАНДА КАТНАШТЫ

**Нурлатның баш китапханәчесе Библиокараванда катнашты**

Нурлат җирлекара китапханәсе директоры Роза Липатова 6 сентябрьдән 11 сентябрьгә кадәр Ярославль шәһәрендә үткән Россия гамәви китапханәләренең "Библиокараван-2015" XIV форумында катнашты.

Роза Липатова сүзләренчә, Библиокараван илебезнең китапханәләр берләге өчен Әдәбият елының иң якты битләреннән берсе булды. Форум Россиянең 24 субъектыннан 200гә якын кешене берләштергән.

– Тәҗрибә уртаклашу өчен бик файдалы булды. Китапханә эшенең алдынгы алымнары белән таныштык. Һөнәри тәҗрибәбезне баетырга мөмкинлек биргән нәтиҗәле һәм кызыклы хезмәттәшлек булды бу. Яңа идеяләрне үзебездә актив тормышка ашырачакбыз, – диде Роза Харисовна.

Моннан тыш, ул борынгы Ярославль буйлап сәяхәт вакытында алган тәэсирләре белән дә уртаклашты. Форум кысаларында алар Ярославльнең истәлекле урыннарында булганнар, туган якны өйрәнү маршруты – Ростов, Борисоглеб, Углич, Переславль-Залесский, Мышкин, Гаврилов-Ям буйлап үткәннәр.

Маргарита ЛИТТА

# Сквер дусларны җыйды



Автор фотосы

СКВЕРДА ҮЗБӘК ДИАСПОРАСЫНЫҢ ҮЗ ЯЛ ЗОНАСЫ БАР

**11 сентябрьдә Нурлатта Парклар һәм скверлар елы кысаларында "Дуслык" скверы тантаналы шартларда ачылды.**

Парк һәм скверларны реконструкцияләү эше районда ТР Президентының указы чыкканчы ук башланган иде инде. Нурлатта парк зоналары төзү һәм реконструкцияләү барышында биш масштаблы проект гамәлгә ашырылачак.

Узган язда шикәрчеләр бистәсендә "Бердәм Россия" партиясенең Нурлат җирле бүлекчәсе инициативасы белән "Дуслык" скверына нигез салынган иде. Быел язын биредә масштаблы эшләр башкарылды.

Проект авторлары фаразлаганча, районда яшәүче халыкларның бердәмлеген һәм милләтара татулыгын чагылдыручы ял зонасы булды ул. Яшел территория тематик зоналарга бүленгән. Аның Халыклар дуслыгы йорты белән күрше булуы да моңа этәргеч бирә. Сквер райондагы милли җәмгыятьләргә мәдәни чаралар уздыру өчен бик җайлы урын булды.

Скверны тантаналы шартларда ачкан район башлыгы Равил Кузюров әлеге ял зонасының нурлатлыларның яраткан урыны булуын теләде.

- Районыбыз күпмилләтле, һәм халыклар үзара тату яши, - диде Равил Әфраимович.

Нурлатлыларның шатлыгын бу көнне "Татнефтепром" җәмгыяте генераль директоры Сергей Щелков, "ТНП-Зүзәйнефть" җәмгыяте генераль директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты Шамил Яһудин, "Татех" җәмгыяте генераль директоры Ирек Хәйруллин, ТРның Халыклар дуслыгы йорты директоры урынбасары Наталья Мясникова, ТРда үзбәк милли-мәдәни автономиясе рәисе Абдуманноб Абдусаттаров уртаклаштылар.

Чара Халыклар дуслыгы йортында зур концерт программасы белән дәвам итте. Бәйрәм көнне нурлатлыларга һәм шәһәр кунакларына Татарстан Халыклар дуслыгы Ассамблеясы һәм Йорты әзерләгән "Дуслар җыелган җирдә" – "Мы вместе – в этом наша сила" дип аталган программа тәкъдим ителде.

Зилия ӘКСАНОВА

ҖӘҺӘТ ӘҢГӘМӘ

## ҖАВАПЛЫЛЫКТАН КАЧЫП БУЛМЫЙ

**Районда юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штраф түләмәүчеләр саны арткан.**

Бүген районда РФ КоАПының 20.25 маддәсе, 1 өлеше буенча тиешле вакытта административ штраф түләмәгән 200гә якын машина йөртүче исәпләнә икән. Шуларның 163е судта каралган. Бу уңайдан ЮХИДИ бүлеге җитәкчесе Рөстәм Гарипов мәнә нәрсәләр сөйләде:

– Әлеге төр кагыйдә бозу – бездә проблемалы моментларның берсе. 77 кешегә карата административ штраф бирелсә, 82 кеше икеләтә күләмдә штрафка, 1 машина йөртүче мәҗбүри эшләргә тартылды. Кагыйдә бозучылар арасында 8-10 түләмәгән штрафлылар да бар. Штрафлардан качып йөрүчеләр юл хәрәкәтендә катнашучыларның барысы өчен дә потенциаль куркыныч тудыра.

**– Штрафлар буенча бурыч җәза дәрәҗәсенә кагыламы?**

– Юк, мисал өчен, июль аенда 20 яшьлек машина йөртүче тиешле срокта юл кагыйдәләре бозган өчен 500 сум күләмендә штраф түләмәгән булган. Суд аңа карата 5 тәүлек арест турында карар чыгарды.

**– Штраф түләмәүчеләр арасында вазифаи затлар очрыймы?**

– Була. Шәһәребездәге бер вазифаи зат кагыйдәләрне бозып, алдагы утырычка ике баласын утыртып йөри. Аның каешны каптырмаган өчен түләнмәгән штрафы бар иде инде. Суд аңа карата мәҗбүри эшләргә тарту турында карар чыгарды.

**– Рөстәм Рамилевич, штрафларны ничек түләтергә була?**

– Штрафларны берничә юл белән кайтарырга мөмкин. ДПС инспекторларын да, суд приставларын да бу эшкә тарту юлы белән. Кагыйдә бозучыларга карата транспортка арест салу кебек чаралар да кулланыла. Бурычлыларның транспорт чараларына арест салына. Моннан тыш, суд приставлары бурычлыларны чит илгә чыгудан тыя. Шул рәвешле, машина йөртүчеләрнең вакытында түләнмәгән штрафы зур проблемалар китереп чыгарырга мөмкин.

**– Күп кешеләр штрафларны түләмәүне вакыт юклыкка, я булмаса банкларда чиратлар булуга бәйли.**

– Хәзер Интернет заманы. Шуңа да түләүләр белән проблемалар юк. Юл хәрәкәте өлкәсендәге штрафлар булу-булмауны һәм түләүләрне Россия Федерациясенең дәүләт хезмәтләре порталында www.uslugi.tatarstan.ru, gibdd.tatarstan.ru онлайн-сервисларында башкарырга мөмкин. Моннан тыш, банк терминаллары эшли.

**– Әңгәмәгез өчен рәхмәт!**

Зилия ӘКСАНОВА сөйләште

# ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА

СОЦИАЛЬ ТАРМАК

## 15 көн эчендә сайлап өлгерергә

**Ташламага ия кешеләрнең соцпакет яисә аның акчалы эквивалентын сайлаулары өчен ярты ай калып бара.** Бу вакыт эчендә алар кайсысына өстенлек бирүләре хакында тагын бер тапкыр уйларга тиешләр. Чөнки дәүләт тарафыннан каралган түләүсез дару препаратлары, ял йортларына юллама һәм башка ташламалар иң беренче чиратта ташламага ия кешенең сыйфатлы дәвалануы һәм сәламәтлегe өчен кирәк. Социаль хезмәтләр җыелмасы 2005 елдан гамәлгә кертелде. Ташламага ия кешеләрне дарулар белән тәэмин итү буенча соңгы 10 елда нинди үзгәрешләр булган?

**Илдар Зәкуанов, үзәк даруханә мөдире:**

*– Нурлат районы үзәк хастаханәсе тарафыннан бирелә торган заявкалар 100 процент диярлек үтәлә. Алар районыбызда яшәүче авыруларның санын һәм категорияләрен исәптә тотып күпкә төгәлрәк төзелә.*

**Вазыйх Гафуров, Нурлат хастаханәсе баш табибының поликлиника эшләре буенча урынбасары:**

*– Беренчедән, рецептлар язганда табиблар комиссиясен үтү механизмы гадиләштерелде. Монда чиратлар юк. Икенчедән, ерак авылларның фельдшерлары ташламага ия кеше өчен поликлиникада рецепт яздырып, аның буенча даруханәдә дару алу хокукына ия. Моның өчен тиешле рөхсәт кәгазе һәм ЦРБ җитәкчелегенең, даруханә һәм шәхсән фельдшерның ризалык белдерүе генә кирәк. Өченчедән, киләчәктә поликлиника-даруханә, ФАП-даруханә электрон чилтәрен булдыру күздә тотыла. Бу глобаль мәсьәләләрнең берсен хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк. Сәламәтлек саклау министрлыгында әлеге мәсьәләне хәл итү планы бар инде.*

**Рушания Шакирова, РФ Пенсия фондының Нурлат районы идарәсе начальнигы:**

*– 7673 ташламага ия кешенең 5747се соцхезмәтләр җыелмасыннан баш тартты. Быел 51 кеше яңадан соцпакетны сайларга булды. Тулаем алганда, федераль ташламага ия кешеләрнең соцхезмәтләр җыелмасына өстенлек бирүе буенча үсеш күзәтелә. Кешеләр уйланылган карарлар кабул итә башладылар.*

Пенсия фондының Нурлат районы идарәсе кабат искәртә: федераль ташламага ия кешеләрнең сайлау өчен санаулы көннәре генә калды. Шуңа күрә, карар кабул итәр алдыннан, социаль хезмәтләр җыелмасы яисә аның акчалы эквивалентының кайсысы мөһимрәк булуы турында яхшылап уйларга кирәк. Әмма шуны истә тоту мөһим: бары тик соцпакет кына югары квалификацияле медицина ярдәмен гарантияли. Бер мисал. Бер инвалидта беренче стадиядәге яман шеш авыруын тапканнар. Химиотерапия курсы 175 мең сум тора. Ташламага ия әлеге авыру соцпакеттан баш тарткан булган. Бер генә дәвалану курсын булса да үтү өчен кирәкле сумманы җыярга аның мөмкинлеге юк. Хәзер ул соцпакетны яңарту өчен гариза язган, әмма аннан ул киләсе елның гыйнвареннан гына файдалана алачак. Ә вакыт бара...

Сирень СӘМӘРХАНОВА

ХУШЛАШУ СҮЗЕ

### ХУШ, ИЛНАЗ!



Атнаны Илназыбыздан башка башлыйбыз. Китте Илназ, бөтенләйгә безне ташлап китте. Моннан соң аның ихластан кеткелдәп көлүләрен ишетмәбез, җыр кебек йөгерек тел белән язылган хәбәрләрен укый алмабыз инде. Бәйрәм, шимбә-якшәмбе белән санашмыйча эшкә чыгучы да, күз ачып йомганчы язманы тәрҗемә итеп ташлаучы да, киткән версткалаучы урынына газетаны калыпка салучы һәм фотоархивтан теләсә кайсы фотоны табып бирүче дә калмады. 15 ел эшләп, гади корректордан мөхәррир урынбасары дәрәҗәсенә җиткән талантлы сүз остасы, нечкә юмор иясе Илназ газетабыз өчен чын хәзинә иде. Югалтуның аннан да үкенечлесе – җәмәгате, хезмәттәшебез Лилияне тол, алма кебек ике баласын ятим калдырып китте. Әнисе, туганнары, якыннары, фикердәшләрен ут эченә салып китте. Үлем аяусыз, иң йомшак күңелле, иң игелекле кешеләрнең җаннарын кыя. Бер генә кешегә дә авыр сүз әйтеп хәтер калдыра белмәгән җор телле, игелекле күңелле Илназ бигрәк озак һәм бәхетле яшәргә тиеш иде дә бит!...

Коллективыбызда матәм көннәре. Калганнарның йөрәк ярасын төзәтерлек җылы сүзләр эзлибез – табылмый, бары вакыт кына җөйләр инде ул җәрәхәтне. Лилия янәшәсендә булып, нәфис иңнәренә төшкән ул хәсрәтне күтәрешергә сабырлыгыбыз җитсен иде, дибез. Сабырлыкның иң зурысы аларның үзләренә – гаиләсенә, әнисенә, туганнарына кирәк – Аллаһтан көч, акыл, түземлек сорыйбыз. Кыска гына гомеренең дәвамчылары булган уллары Булат белән Камил тәүфыйклы, акыллы, әниләренә терәк булып үссеннәр иде, дип ялварабыз. Илназыбызның кабере нурлы, рухы шат булсын, дип телибез. Бүген аңа – мәрхүм Илназ Мөбарәкшинга дөньялыктан бары шул гына кирәк...

КЫСКАЧА

### НУРЛАТТА ЙӨЗЬЯШӘРНЕ КОТЛАДЫЛАР

12 сентябрьдә районның өлкән кешеләреннән берсе - Мәгъсүмә Әбҗапбарова үзенең 100 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтте. Юбилярны гомер бәйрәме белән район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова тәбрикләде. Флюра Рәшитовна юбилярга РФ Президенты Владимир Путинның Рәхмәт хатын һәм район башлыгы Равил Кузюровның бүләген тапшырды. Йөз яшьлек Мәгъсүмә апа сугыш, ачлык, коллективлашу елларын кичергән.

Тумышы белән Киекле авылыннан булган Мәгъсүмә апа 15 яшеннән Кировта торф чыгаруда булган, аннан Казанда тавык фабрикасында эшләгән. Кайда гына эшләсә дә, туган ягы - Киеклесе үзенә тарта аны. Шуңа да ул гаиләсе белән авылына кайтып төпләнгән. Бүген ул бертуганының кызы тәрбиясендә яши.

- Ходай ярдәме белән бүгенге көнемә җиттем, - ди юбиляр тормышына шөкерана итеп.

Зилия ӘКСАНОВА

## Районда кышлату чорына әзерләнәләр

**Узган атнада "Нурлат сөте" ОООсының Сәләнгеш бүлекчәсе базасында азык әзерләү һәм терлекләрне кышлату сезонына күчерүгә багышлап авыл хуҗалыгы семинары үткәрелде.**

Аның эшендә район башлыгы Равил Кузюров катнашты һәм алда торган бурычларны билгеләде.

Район буенча бүгенге көнгә бер баш шартлы терлеккә 21 центнердан артыграк азык әзерләнгән. Әмма бу чик түгел, чөнки хуҗалыклар шул көннәрдә кукуруз урдырырга һәм силос салырга керештеләр. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин әйтүенчә, район буенча кукуруз мәйданнары 4500 гектардан артыграк, һәм бу бер баш терлеккә тагын 10 берәмлек чамасы азык әзерләргә мөмкинлек бирәчәк. Семинарда исә силос салуның технологик таләпләре турында җентекләп аңлатылды һәм иң беренче чиратта сыйфатлы азык әзерләүгә игътибар бирергә кирәклеге әйтелде. Семинарда катнашучылар бүлекчәдә силос салуның барышын да карадылар. Бирегә быел күрсәткечләр аеруча яхшы – инде бүгенге көнгә бер баш шартлы терлеккә 26 центнердан артыграк азык әзерләнгән.

Терлекләрне кышлату сезонына күчерүгә килгәндә, Сәләнгештә шул көннәрдә бозаулату бүлеген фермаларга күчерергә өлгергәннәр инде. Гомумән, хуҗалыкның һәр 4 бүлекчәсендә фермалар кышлату сезонына әзер, быел Урта Чаллыдагы ике ферма республика программасы буенча реконструкцияләнде. Якын араларда бар терлекләрне дә көтүлекләрдән фермаларга күчерергә планлаштыралар.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

ДОСТАВКА ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС И ЖОМ
8-937-280-94-84.

Пеноизол, утепление стен и потолков домов жидким пенопластом.
Т.: 8-937-600-33-02, 8-987-233-32-18.

Уважаемые родители будущих первоклассников!
МАОУ «Средняя общеобразовательная школа №2» г.Нурлат объявляет набор детей на занятия по подготовке к школе «Скоро в школу», которые будут проводиться с 3 октября 2015 г. по 30 апреля 2016 г.
Организационное родительское собрание состоится 22 сентября 2015 г. в 17.15 в актовом зале школы по адресу: ул. Школьная, д.9.
БУДЕМ РАДЫ ВСТРЕЧЕ С ВАМИ!

ПАМЯТНИКИ, ФОТО НА ГРАНИТЕ. ДОСТАВКА. УСТАНОВКА. ЦЕНА ДОГОВОРНАЯ.
Ул. Ленинградская, 14.
Т. 8-987-420-05-97.

БЛОКИ ДОЛОМИТОВЫЕ СТЕНОВЫЕ,
40 руб./штука. Доставка.
Т. 8-927-402-00-75.

- Профнастил (9; С10; С20; С21; 7НС-44),оцинкованный, окрашенный под камень, дерево
- Сайдинг металлический, виниловый
- Доборные элементы
- Пароизоляция
- Водосточные системы
- Штакетник
- Профильные трубы
Кредит (предоставляют АО «ОТП Банк», АО «Альфа-Банк»).
Доставка. Выезд на замер бесплатно.
г.Нурлат, универсальный рынок, магазин «Инструментград».
Тел.: 8-937-579-24-24, 8-987-409-27-06.

ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА «KRAUSS»
С 1 января по 31 декабря 2015 г. при заказе 5 окон, 6-е в подарок*
Деревенские окна по 2000 руб.
Откосы, подоконники, москитные сетки.
Работаем по всему Татарстану.
Рассрочка без % (предоставляет ИП Ахметов Ф.Ф.).
*подробности по т.: 8-9274-000-606, 8-9272-449-000,
ИП Ахметов Ф.Ф.

В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:

19 сентября 2015 года
1. Терапия, кардиология, ревматология.
2. Педиатрия-кардиология.
3. Неврология.
4. Сосудистая хирургия, новый революционный метод при варикозной болезни вен, не требующий госпитализации и наркоза. Помощь при сосудистых звездочках.
5. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное допплеровское картирование), исследования сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей.

20 сентября 2015 года
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии, ведение беременности.
2. Диетология.
3. Эндокринология.
4. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

26 сентября 2015 года
1. Гастроэнтерология.
2. Онкогинекология-эндокринология.
3. Кардиология, ревматология.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное допплеровское картирование).

27 сентября 2015 года
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии, ведение беременности.
2. Диетология.
3. Отоларингология.
4. Аллергология. Иммунология. Решение проблем бронхиальной астмы, аллергических дерматитов, кожных заболеваний.
5. Урология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
6. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

КДЦ предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан».
Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.

ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.
Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста
Реклама

19 СЕНТЯБРЯ в здании типографии (ул. К.Маркса, 19) с 8.00 до 16.00 состоится
ВЫСТАВКА-ПРОДАЖА. ЖЕНСКИЕ ПАЛЬТО, ПЛАЩИ.
Производство России.
Модные модели на любой возраст (размеры 42-66).

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ

Кадастровым инженером Зайнутдиновым Ильназом Хафизовичем (квалификационный аттестат № 16-11-365 , почтовый адрес: РТ, г.Нурлат, ул.Кооперативная, д. 2. Тел: 89297229593, email, status.zk@yandex.ru) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей, из земель паевого фонда с кадастровым номером 16:32:000000:1081, общей площадью 52200 кв.м расположенного по адресу: РТ, Нурлатский муниципальный район, Новоиглайкинское сельское поселение.

Заказчик проекта межевания - Сатдаров Халил Салихович. Почтовый адрес: РТ, Нурлатский муниципальный район, д. Светлое Озеро, ул. Речная, д. 41. Тел: 89274317355.

С проектом межевания можно ознакомиться в течение 30 дней с момента опубликования данного извещения по адресу: Республика Татарстан, г.Нурлат, ул.Кооперативная, д.2, с 8-00 до 17-00, тел. 8-(84345) 2-25-75.

Порядок предоставления возражений после ознакомления с проектом межевания относительно размера и местоположения земельного участка, выделяемого в счет земельных долей, указан в ст.13 – ст.14 ФЗ от 24.07.2002 г. № 101-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения». Обоснованные возражения необходимо направлять в течение 30 дней с момента опубликования данного извещения по адресу: Республика Татарстан, г.Нурлат, ул.Кооперативная, д.2, ООО «Статус».